РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ГЛАВА ЕГОРКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЕГОРКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Егоркино ав. КАРАР

«5» ноябрь 2020 ел № 3

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Каравыл Тавы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Егоркино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1.2020 елның 19 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Каравыл Тавы авылы Завод урамы буенча 2 нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Каравыл Тавы авылы Завод урамы буенча 1-7нче, Төзүчеләр урамы буенча 1-3нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 19 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта минутта Каравыл Тавы авылы Дала урамы буенча 3 нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Каравыл Тавы авылы Дала урамы буенча 1-37нче, 4-52нчы, Кузнецов урамы буенча 2-16нчы, 1-27нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2020 елның 19 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта минутта Каравыл Тавы авылы Мичурин урамы 23нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Каравыл Тавы авылы Мичурин урамы буенча №1-67нче, №2-62 йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2020 елның 18 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Каравыл Тавы авылы Мәктәп урамы буенча 31Б адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Каравыл

Тавы авылы Мәктәп урамы №5-77, №4-102 нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Халык җыенын үткәрү өчен Каравыл Тавы торак пунктында яшәүчеләрнең исемлеген аеруга сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегенең Каравыл Тавы авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Торак пункт чикләрендә юлларны ремонтлау.

Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

« РИЗА» «КАРШЫ».

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә)һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Каравыл Тавы авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Егоркино авыл җирлеге башлыгы А.И.Борисов